Татарстан Республикасы Кукмара муниципал районы
Чарлы авыл җирлеге Советы

# КАРАР

19 август 2024 ел №20

Чарлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 06 июнендәге 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Чарлы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Чарлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 06 июнендәге 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, Чарлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 23 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 13 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 37 номерлы, 2024 елнын 11 июненнэн 13 номерлы, 2024 елнын 16 июленнэн 15 номерлы

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү нормативтан артмаган күләмдә түләнә: 11 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 14,12 айлык акчалата түләү 12 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 12,86 айлык акчалата бүләкләү.»;

1.2. 3 өлешнең 3.4 пунктчасында «(хезмәттәге катлаулылык, киеренкелек, югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н.Козлов